**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы,423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-07, chishma@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2026 елның «10» июненнән № 143

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Яңа Чишмә авыл җирлеген 2035 елга кадәр чорга җылылык белән тәэмин итү схемасы проектын карау (2027 елга актуальләштерү) буенча гавами тыңлаулар билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 28 статьясы, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты турында нигезләмә, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль муниципаль районы» берәмлегендә гавами тыңлаулар оештыру һәм уздыру тәртибе турында Нигезләмәне раслау хакында» 2021 елның 30 сентябрендәге 14-105 номерлы карары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Җылылык белән тәэмин итү схемаларына таләпләр, аларны эшләү һәм раслау тәртибе турында» 2012 елның 22 февралендәге 154 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Яңа Чишмә авыл җирлеген 2035 елга кадәр җылылык белән тәэмин итү схемасы проектын карау (2027 елга актуальләштерү) буенча гавами тыңлаулар билгеләргә (алга таба – Җылылык белән тәэмин итү схемасы).

1.1. Гавами тыңлауларны 2026 елның 22 июнендә 14.00 сәгатьтә, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы бинасында, Татарстан Республикасы, Яңа Чишмә районы, Яңа Чишмә авылы, Совет урамы, 80 нче йорт адресы буенча үткәрергә.

1.2. Фикер алышына торган мәсьәлә буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр 2026 елның 17 июненә кадәр эш көннәрендә 08.00 сәгатьтән 17.00 сәгатькә кадәр түбәндәге адрес буенча кабул ителә: Татарстан Республикасы, Яңа Чишмә районы, Яңа Чишмә авылы, Совет урамы, 80 нче йорт, 304 нче каб.

1.3. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Яңа Чишмә авыл җирлеген 2035 елга кадәрге чорга җылылык белән тәэмин итү схемасы проектын карау (2027 елга актуальләштерү) буенча гавами тыңлауларда кергән искәрмәләрне һәм тәкъдимнәрне җыю өчен карарга кушымта нигезендә түбәндәге составта эш төркеме төзергә.

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Камалетдинов Дамир Рөстәм улына йөкләргә.

Җитәкче Р.Р. Фасахов

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы
Башкарма комитетының
2026 ел елның «10» июнендәге
143 номерлы карарга
кушымта

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Яңа Чишмә авыл җирлеген 2035 елга кадәрге чорга җылылык белән тәэмин итү схемасы проектын карау (2027 елга актуальләштерү) буенча гавами тыңлауларда кергән искәрмәләрне һәм тәкъдимнәрне җыю өчен эш төркеме составы

| № т/б | Фамилиясе, исеме, атасының исеме | Вазифасы |
|---|---|---|
| 1 | Фасахов Ринат Рифгать улы | Татарстан Республикасының Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе |
| 2 | Камалетдинов Дамир Рөстәм улы | Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары |
| 3 | Кәбирова Диләрә Нәкыйп кызы | Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының төзелеш, архитектура һәм ТКХ бүлеге башлыгы |
| 4 | Әхмәтова Линүзә Ленар кызы | Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының төзелеш, архитектура һәм ТКХ бүлеге баш белгече |
| 5 | Попкова Наталья Владимировна | Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Милек һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы рәисенә |
| 6 | Иванов Алексей Вячеславович | Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы «Яңа Чишмә торак-коммуналь хуҗалыгы» муниципаль унитар предприятиесе директоры |
| 7 | Маланчева Татьяна Николаевна | Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Яңа Чишмә авыл җирлеге Башкарма комитеты җитәкчесе |